# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 42-1 «01» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 13 июлендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, « Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 13 июлендәге 10-1 номерлы карары белән(2023 елның 29 маендагы 28-2 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң «Яңа тормыш» район газетасында (Новая жизнь), Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http// spasskiy.tatarstan.ru) һәм httr//pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитетына йөкләргә.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге
башлыгы Ф.В. Мөхәммәтов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 01 ноябрендәге 42-1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр

**1. Уставның 5 статьясында:**

1 өлешнең 4 пунктындагы 4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;";

1 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5) җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне кертеп, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм җирлек торак пунктлары чикләрендәге юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

1 өлешнең 28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«28) җирле әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

1 өлешнең 30 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«30) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 40 пункт өстәргә::

«40) җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру;»;

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә::

«41) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;»;

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 42 пункт өстәргә::

«42) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман кору чараларын гамәлгә ашыру;»;

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 43 пункт өстәргә::

«43) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм чаралар үткәрү, әлеге күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү;»;

часть 1 дополнить пунктом 44 следующего содержания:

«44) осуществление учета личных подсобных хозяйств, которые ведут граждане в соответствии с Федеральным законом от 7 июля 2003 года N 112-ФЗ "О личном подсобном хозяйстве", в похозяйственных книгах.».

**2. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:**

«5. аларга чит ил агенты статусы алу.».

**3. Уставның 49 статьясында:**

1 өлешнең 2 пунктына уникенче абзац өстәргә:

«-җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрү;»;

1 өлешнең 3 пунктындагы тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

1 өлешнең 3 пунктына уникенче абзац өстәргә:

«-җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны һәм мондый зыянны бетерүне оештыруны гамәлгә ашыра;»;

1 өлешнең 3 пунктына унөченче абзац өстәргә :

"- җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру турында Карар кабул итә;»;

1 өлешнең 3 пунктына ундүртенче абзац өстәргә :

"- җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман кору чараларын гамәлгә ашыра;»;

1 өлешнең 4 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итә, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) эшчәнлеген булдыруны һәм тәэмин итүне, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»

1 өлешнең 5 пунктына дүртенче абзац өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар хуҗалык алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә ала.».

1 өлешнең 6 пунктының ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

1 өлешнең 9 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра.».

**4. Уставның 30 статьясындагы 9 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.».**

**5. Уставның 68 статьясында:**

1 өлешнең 1 пунктында “, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,”

сүзләрен өстәргә;

1 өлешнең 2 пунктында «йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;»;

2 өлештә «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.

**6. Уставның 78 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::**

"78 маддә. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе.

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми игълан итү булып түбәндәгеләр тора:

1) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында тулы текстны рәсми бастырып чыгару https://pravo.tatarstan.ru (ЭЛ № ФС77-60244 массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 2013 елның 17 декабрендә Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә вакытлы матбугат басмасында - "Яңа тормыш" ("Новая жизнь") район газетасында (газета массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә законнарны үтәүгә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсендә теркәлгән, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык һәм 2007 елның 30 ноябрендәге ПФС-4762 номерлы Федераль хезмәт) тарафыннан бирелгән;

2) Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру: http:/ spasskiy.tatarstan.ru.

3. Гражданнардан файдалана алуны тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары гамәлдә. Адресы: Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы 19 йорт.

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 10 эш көне эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка игълан ителә.

5. Шәһәр җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән

үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә (рәсми басылып чыгудан тыш) Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.

**7. 88 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:**

«12) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның «$15^{2}$»статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр))";